КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 7 март г.Казань № 139

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү проектларын сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм Электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү өчен сәнәгать технопаркларындагы идарәче компанияләренең документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 19 декабрь, 1639 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү проектларын сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм Электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү өчен сәнәгать технопаркларындагы идарәче компанияләренең документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 19 декабрь, 1639 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20242 ел,

18 октябрь, 899 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү өчен сәнәгать технопаркларындагы идарәче компанияләренең документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

түбәндәге эчтәлекле 3.2 пункт өстәргә:

«3.2. Белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкалар кабул итү тәмамлану датасы башланудан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында билгеләнгән белдерү ясау тәртибе кебек тәртиптә түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 5.7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкага үзгәреш кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, белдерүгә үзгәрешләр кертү турында хәбәр ителә.»;

5.3 пунктның «п» пунктчасындагы җиденче абзацында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

6.5 пунктта татар текстында «комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләрен «комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

6.8, 6.9 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

6.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.13. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчеләрне билгеләү максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе төзелә, ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән

соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе аңа имза куелган көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

7.1 пунктның беренче абзацында «Электрон бюджет» системасында» сүзләреннән соң «(техник мөмкинлек булганда)» сүзләрен өстәргә;

7.2 пунктта:

«г» пунктчасында татар текстында «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

«з» пунктчасында татар текстында «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү проектларын сайлап алуны үткәрү тәртибенең 2.5 пунктындагы «п» пунктчасының җиденче абзацында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин